Аксубай муниципаль районы Беловка авыл жирлеге Советы
423050 Аксубай районы,Яңа Үзи авылы,
Мәктәп урамы, 7 нче йорт

Совет Беловского сельского поселения Аксубаевского муниципального района
423050 Аксубаевский район,с.Новое Узеево улица Школьная, д.7

Тел. (8-84344-4-08-19) ОГРН 1061665003212,
ОКПО 04306440, ИНН/КПП 1603005000/160301001
E-mail: *Belov.Aks@tatar.ru, sovet.belov@mail.ru*

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

№ 7 от 01.11. 2021 г

Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Сергеевский авылында гражданнарның үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 ст. нигезендә

Карар бирәм:

1. ТР, Аксубай районы, Сергеевский авылы, Яшел урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 2021 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Сергеевский авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сергеевский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? :

**1.Беловка авыл җирлеге Сергеевский торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**
--Сергеевский торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: грунт күтәрү, грейдлау, вак таш салу, тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- авыл юлларына вак таш җәю өчен вак таш сатып алу
- Беловка авыл җирлегенең Сергеевский торак пункты чикләрендә юлларны кыш көне карап тоту (юлларны кардан чистарту, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**2. КККНЫ җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**
- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу;
«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:/ / pravo. tatarstan. ru)бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы И. Р. Мәхмүтов